КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 май г.Казань № 358

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибе» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибе» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 август, 557 нче; 2018 ел, 15 сентябрь, 784 нче; 2019 ел, 19 март, 191 нче;

2019 ел, 28 август, 709 нчы; 2020 ел, 20 июль, 609 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда» сүзләрен «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта татар текстында «гамәлгә ашыру өчен 2020 елда» сүзләрен «гамәлгә ашыру өчен 2021 елда» сүзләренә алмаштырырга, «2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда» сүзләрен «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

икенче абзацта «2020 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибен» сүзләрен «2020 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибен» сүзләренә алмаштырырга, «2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда» сүзләрен «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда» сүзләрен «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына 2020 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына 2021 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибе»;

1 пунктта татар текстында «2020 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибен һәм шартларын» сүзләрен «2021 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибен һәм шартларын» сүзләренә алмаштырырга, «2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда» сүзләрен «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«табиб-белгечнең аерым категорияләрдәге гражданнарны торак белән тәэмин итү буенча башка федераль һәм республика программаларында гариза бирүченең катнашуы турындагы шартнамә буенча үтәлмәгән финанс йөкләмәләре булмау.»;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Табиб-белгеч бу Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән йөкләмәләрнең бишьеллык срогы тәмамланганга кадәр вафат булган очракта, грант акчасыннан файдалану хокукы гаиләнең башка әгъзасына күчә.»;

әлеге карар белән расланган 2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибе»;

1 пунктта «2019 елның III – IV кварталларында һәм 2020 елда» сүзләрен «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин